# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге Утар-Аты авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**“11” ноябрь 2025 ел** **№ 1**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2025 елның 11 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

“ Сез 2026 елда Утар Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналаынр, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешенең өслек һәм тигезләгеч катламнарын ясау өчен вак таш сатып алу, мини-төягеч хезмәтләре өчен түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу, балалар өчен уен мәйданчыгы киртәсен урнаштыру өчен материал сатып алу )
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материаллар сатып алу, су җыю манарасы территориясендә койма урнаштыру)?”

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 251 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 146 раждан кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 146 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар- Аты авыл җирлегендә Утар-Аты авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. “ Сез 2026 елда Утар Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналаынр, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешенең өслек һәм тигезләгеч катламнарын ясау өчен вак таш сатып алу, мини-төягеч хезмәтләре өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу, балалар өчен уен мәйданчыгы киртәсен урнаштыру өчен материал сатып алу )

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материаллар сатып алу, су җыю манарасы территориясендә койма урнаштыру)?”

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

ӘЙЕ» -146 “КАРШЫ“-0

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Утар - Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева